**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.03.2021 Балык Бистәсе п.г.т. №49пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 2 декабрендәге 255п номерлы карары белән расланган «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Норматив хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 20 гыйнварындагы 68-р номерлы күрсәтмәсенә таянып КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 2 декабрендәге 255п номерлы карары белән расланган «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» Муниципаль программасына ( алга таба-Программа) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Программаның III пунктына түбәндәге эчтәлекле пунктча өстәргә: "Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 20.01.2001 ел, № 68–р күрсәтмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетына 2021 елда 172 550,00 (Йөз җитмеш ике мең биш йөз илле) сум 00 тиен күләмендә башка бюджетара трансфертлар бирелә".

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге» МКУ начальнигы И.З. Шакировка йөкләргә.

Җитәкче Р.Л. Исланов